ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е К А Р А Р

21 сентябрь 2015 ел № 817

Нурлат муниципаль районында 2015-2016 уку елында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турындагы нигезләмәне раслау хакында" 1999 елның 31 декабрендәге 1441 номерлы, "оборона турында" 31.05.96 статьясындагы 61-ФЗ номерлы, "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында" 28.03.98 елгы 53-ФЗ номерлы карарларын үтәү һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүне камилләштерү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

-2015-2016 уку елында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча төп чаралар планы;

- Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы буенча бүлеге буенча гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүне контрольдә тоту комиссиясе составы.

- гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү, хәрби хезмәткә чакыруны оештыру һәм үткәрү буенча ТР Хәрби комиссариатының Нурлат шәһәре буенча бүлеге буенча комплекслы тикшерүләр графигы

2. Район оешмалары, предприятиеләре һәм учреждениеләре җитәкчеләренә, мәгариф буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге начальнигына хәрби хезмәткә чакырылуга кадәрге яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләү буенча кирәкле чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

3. Нурлат ДОССАФ, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә тәкъдим итәргә:

3.1. яшьләрне хәрби-гамәли спорт төрләре белән шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен хәрби-спорт секцияләре һәм клублары булдыру мөмкинлеген карарга.

4. Нурлат шәһәренең "халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ДКУ директорына билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган вакытлыча эшләмәүче призывниклар арасыннан хәрби-хисап белгечлекләре буенча гражданнарны әзерләүне оештырырга тәкъдим итәргә:

5. Нурлат муниципаль районы башкарма комитетына хәрби хезмәткә чакырылуга кадәрге яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләүгә җәлеп ителә торган белем бирү учреждениеләрендә хәрби-хисап белгечлекләре буенча гражданнарны әзерләүне оештырырга.

6. "Нурлат РҮХ" ДАССОның баш табибына профилактик медицина тикшерүләре нәтиҗәләре буенча, шулай ук хәрби исәпкә куелганнан соң һәм хәрби хезмәткә чакыру нәтиҗәләре буенча 15-16 яшьлек егетләр белән дәвалау-

сәламәтләндерү чараларының вакытында һәм тулы булуын тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

7. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, башкарма комитетның мәгариф бүлеге, яшьләр һәм спорт бүлеге белән берлектә яшьләрне патриотик тәрбияләү, хәрби хезмәткә чакырылучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын социаль яклау буенча агитация-массакүләм чаралар үткәрергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни үсеш буенча җитәкче урынбасарына йөкләргә.

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К. Габдуллин